**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**Иж-Бобьинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Иж-Бубый авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**28.03.2019** Иж-Бубый авылы № **44-2**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлегендә шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларга үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәлек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 29 июленнән 217-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 гыйнварыннан 32-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеген шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

а) 4.1.2. пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.1.2. Торак пунктлар чикләрендә билгеләнелә торган территориаль зоналар составына авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары (шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләре зоналары), шулай ук авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар белән шөгыльләнүче һәм авыл хуҗалыгын алып бару, бакчачылык һәм яшелчәлек, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны үстерү өчен билгеләнгән зоналар да кертелә ала.»

б) 2.2.2. пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

“2.2.2. Торак зоналарда аерым төзелгән яисә төзелгән социаль һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар, сәламәтлек саклау объектлары, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми һәм урта гомуми белем бирү объектлары, дини биналар, автомобиль транспорты стоянкалары, гаражлар, гражданнар яшәүгә бәйле һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясамый торган объектлар урнаштыру рөхсәт ителә. Торак зоналар составына шулай ук бакчачылык алып бару өчен билгеләнгән территорияләр дә кертелергә мөмкин.”

2. Әлеге карарны Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Иж-Бубый авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка

игълан итәргә http://agryz.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Карарны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында раслау датасыннан биш көннән дә артмаган вакытка урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге Советының Финанс-бюджет, социаль Законлылык һәм хокук тәртибе комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе Р.Р. Ваһапов